КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 26 гыйнвар г.Казань № 35

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы «Республика ветеринария лабораториясе» дәүләт бюджет учреждениесенә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 4 апрель, 308 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы «Республика ветеринария лабораториясе» дәүләт бюджет учреждениесенә субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы «Республика ветеринария лабораториясе» дәүләт бюджет учреждениесенә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 4 апрель, 308 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы «Республика ветеринария лабораториясе» дәүләт бюджет учреждениесенә субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу буенча дәүләт программасы турында» 2012 елның 14 июлендәге 717 номерлы, «Бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатлар өчен субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен ачыклый торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы карарлары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм анда Татарстан Республи-

касының «Республика ветеринария лабораториясе» дәүләт бюджет учреждениесенә (алга таба – ветеринария лабораториясе) «Халыкара кооперация һәм экспорт» илкүләм проекты составына керә торган «Агросәнәгать комплексы продукциясе экспорты» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында илкүләм аккредитация системасында ветеринария лабораториясен аккредитацияләү өлкәсен киңәйтү өчен 2019 елдан башлап (субсидия алу елын кертеп) ветеринария лабораториясенең тотылган чыгымнарының бер өлешен, шул исәптән түбәндәгеләрне каплау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба – субсидия) бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибе ачыклана:

ветеринария лабораториясе бинасын (бүлмәләрен), виварияне реконструкцияләү, капиталь ремонт яисә агымдагы ремонт ясау чыгымнарын;

җиһазларны модернизацияләү һәм (яисә) сатып алу чыгымнарын;

ветеринария лабораториясе хезмәткәрләрен укыту чыгымнарын;

лабораторияләр арасында чагыштырма сынаулар уздыру чыгымнарын;

лаборатория җиһазы сатып алу чыгымнарын.»;

2.1 пунктның «в» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«лаборатория җиһазы сатып алуга:

лаборатория җиһазы сатып алуга шартнамәләр күчермәләрен;

накладной һәм (яисә) универсаль тапшыру документлары, счет-фактуралар (булганда), әлеге хезмәтләрне, башкарылган эшләрне кабул итү актлары күчермәләрен;»;

2.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Ветеринария лабораториясенә әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында каралган максатларга бирелә торган субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = Z_р + Z_м + Z_о + Z_i + Z_l,$$

монда:

$Z_р$ – ветеринария лабораториясе бинасын (бүлмәләрен), виварияне реконструкцияләү, капиталь ремонт яисә агымдагы ремонт ясау чыгымнары;

$Z_м$ – җиһазларны модернизацияләү һәм (яисә) сатып алу чыгымнары;

$Z_о$ – ветеринария лабораториясе хезмәткәрләрен укыту чыгымнары;

$Z_i$ – лабораторияләр арасында чагыштырма сынаулар уздыру чыгымнары;

$Z_l$ – лаборатория җиһазы сатып алуга шартнамәләр күчермәләре.

Ветеринария лабораториясе тарафыннан әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында каралган максатларга тотылган чыгымнар әлеге Тәртипнең 2.1 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән документлар белән расланырга тиеш.

Субсидия күләме әлеге Тәртипнең 1.5 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Ветеринария идарәсенә билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларыннан артмаска тиеш.».

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин